**Татар гомуми белем бирү оешмаларында укучылар өчен татар әдәбиятыннан олимпиада сораулары**
**(муниципаль тур, 2023-2024 уку елы) 11 нче сыйныф**

**Үткәрү вакыты- 180 минут**
**Максималь балл – 52 балл**

## I. Теоретик тестлар (10 балл).

1. Әдәбиятның билгеле бер тарихи вакыт аралыгындагы хәрәкәте (1 балл):
1) әдәби барыш (процесс)
2) әдәбият тарихы
3) әдәбият белеме

2. Әдәби әсәрдә эмоциональ-мәгънәви көчкә ия кисәк, образның бер өлеше (1 балл):
1) лейтмотив
2) архетип
3) деталь

3. Гражданлык лирикасы үрнәкләре генә күрсәтелгән рәтне сайлап алыгыз (1 балл):
1) «Кичер, илем!», «Иртә төшкән кар», «Җырларым»
2) «Җырларым», «Тынма, давыл!»
3) «Тынма, давыл!», «Төрмәдә төш»

4. Күрсәтелгән образлар арасыннан кайсы әсәрдә символ вазифасын үти (1 балл):
1) Ә.Еникинең «Төнге тамчылар» әсәрендә портфель
2) Х.Вахитның «Беренче мәхәббәт» әсәрендә бер саны
3) Ф.Хөснинең «Йөзек кашы» әсәрендә йөзек кашы

5. Кечкенә күләмле, эмоциональлеге, ритмик төзелеше белән шигъри сөйләмгә якын булган һәм хис-кичерешләрнең үсеш-үзгәрешен күрсәтә торган чәчмә әсәр (1 балл):
1) нәсер
2) поэма
3) дастан

6. Эпик әсәрләр генә булган рәтне билгеләгез (1 балл):
1) «Төнге тамчылар», «Колыма хикәяләре», «Йөзек кашы»
2) «Беренче мәхәббәт», «Хөсрәү вә Ширин», «Йөзек кашы»
3) «Өч аршын җир», «Кыйссаи Йосыф», «Йөзек кашы»

7. Билгеләмәне игътибар белән укыгыз һәм аңа туры килгән төшенчәне язып куегыз: «*Яшәешнең, кеше табигатенең асылын төгәл, дөрес итеп гәүдәләндерүче иҗат юнәлеше (тибы)*» (2 балл):

Җавап: _____________

8. Иҗат юнәлешләрен татар әдәбиятында формалаша бару тәртибендә урнаштырыгыз. Җавабыгызда алар алдына куелган саннарны гына үсә бару тәртибендә языгыз (2 балл):

1) реализм
2) көнчыгыш романтизмы
3) модернизм

Җавап:_______

ИНСТРУКЦИЯ: Биремнең җавабы булып, саннар тезмәсе генә килә ала. Җавапны буш ара калдырмыйча, өтер яки башка символларсыз языгыз.

## II. Әдип иҗатына кагылышлы биремнәр (32 балл).

1. «Татарча язу танучы һәм бу дәфтәрне укучы дуска!

Моны татарның билгеле шагыйре … язды. Аның тарихы болай: ул 1906 елда туган. Квартиры Казанда һәм Мәскәүдә. Илдә иң зур шагыйрьләрдән санала. 1942 елны сугышка китте һәм әсир төште. Әсирлектә күп азаплар чигеп, кырык үлемнән калып, ахырында Берлинга китерелде. Берлинда сәяси яшерен оешмада катнашуда, совет пропагандасы таратуда гаепләнеп, кулга алынды, төрмәгә ябылды. Бәлки, аны үлем җәзасына хөкем итәрләр. Ул үләр. Ә аның әсирлектә һәм тоткынлыкта язган 115 шигыре бар. Ул шулар өчен кайгыра…» Әлеге юлларның авторы кем? (2 балл):

Җавап:_______

2. Муса Җәлил әдәбиятның кайсы жанрларында эшли (1 балл):

1) либретто, лирик шигырь, повесть
2) лирик шигырь, нәсер, поэма
3) лирик шигырь, поэма, либретто

3. М.Җәлилнең «Кичер, илем!» шигыреннән алынган әлеге өзекнең төп фикере нинди? Дөрес җавапны билгеләгез (2 балл):

*Тик бер өмит: кара август төне*
*Илтер мине шунда җитәкләп.*
*Өстен килер түбән әсирлеккә*
*Үч һәм илгә керсез мәхәббәт.*

*Тик бер өмит, дуслар: сезнең сафта*
*Табар соңгы көрәш теләген.*
*Яраланган, ләкин тар коллыкка*

*Баш имәгән керсез йөрәгем.*

1) шагыйрь йөрәге үлемсез

2) әсир булганда да шагыйрь йөрәгендә илгә керсез мәхәббәт яши, шул мәхәббәт тар коллыкта да горур булып калырга көч бирә

3) Туган илгә мәхәббәт – илаһи көч

4. М.Җәлилнең «Кичер, илем!» шигыреннән алынган әлеге өзектә лирик геройга бәя бирү өчен нинди символик образ кулланыла һәм ул нинди мәгънәдә килә? (2 балл):

*Чаян чага үзен соңгы чиктә,*
*Бөркет ярдан түбән ташлана.*
*Мин соң бөркет түгел идеммени,*
*Баш ияргә шуннан башкага!*

*Ышан, илем, шундый бөркет идем*
*Мин дә, соңгы минут килгәндә.*
*Әзер идем мәгърур канат җәеп*
*Ташланырга ярдан түбәнгә.*

Җавап:_______

5. М.Җәлил шәхесе белән бәйле төбәкләр урын алган рәтне күрсәтегез (1 балл):

1) Минзәлә, Казан, Мәскәү

2) Волхов, Оренбург, Санкт-Петербург

3) Казан, Мәскәү, Арча

6. М.Җәлил әдәбиятның кайсы чорында актив иҗат эше белән шөгыльләнә? Дөрес җавапны билгеләгез (1 балл):

1) 1915-20 еллар

2) XX йөз башы

3) Сугыш чоры

7. М.Җәлилнең «Кичер, илем!» шигыре әдәбиятның кайсы төренә һәм аның нинди жанрына карый? (2 балл):

Җавап:_______

8. М.Җәлилнең «Кичер, илем!» шигыреннән алынган әлеге өзектә кулланылган 2 тел-сурәтләү чарасын табып языгыз (4 балл):

*Кичер мине, илем, синең бөек*
*Исмең белән килеп сугышка,*
*Данлы үлем белән кұмалмадым*

*Бу тәнемне соңгы сулышта.*

*Юк, мин сине тузан бөртегедәй*
*Сансыз гомерем өчен өчен сатмадым.*
*Волхов шаһит: изге сугыш антын*
*Соң чиккәчә керсез сакладым...*

Җавап:_______

9. Муса Җәлилнең «Ялгыз учак» шигырендә лирик геройга бәя бирегез. (5 балл):

*Төн караңгы, учак яктым,*
*Тирә-ягым томан...*
*Мин диңгездә япа-ялгыз*
*Йөзгән кораб сыман.*

*Учагымның чаткылары*
*Томан ертып оча...*
*Чаткыларның яктылары*
*Киң бушлыкны коча.*

*Кызыл ялкын, телен сузып,*
*Уя җирнең битен.*
*Мин кайвакыт я сызгырып,*
*Яхут җырлап куям.*

*Томан аша ялтыраган*
*Утны күрмәсләрме?*
*Томан ертып ялтыраган*
*Җырга килмәсләрме?*

10. Әлеге шигырьдә автор нинди фикерләр үткәрә, учак образы нинди мәгънәләрдә кулланыла? (6 балл)

11. Муса Җәлил иҗатына хас 3 сыйфатны, үзенчәлекне атагыз (6 балл).

**III. Иҗади бирем (10 балл).**

«Тел, Моң, Хәтер – рухның таяныч нигезе ул...» юлларына нигезләнеп, 18 җөмләдән ким булмаган күләмдәге инша языгыз.